ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
**ЗАКОНЫ**

# «Татарстан Республикасында халыкка адреслы социаль ярдәм күрсәтү турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы тарафыннан
2021 елның 11 июнендә
кабул ителде

**1 статья**

«Татарстан Республикасында халыкка адреслы социаль ярдәм күрсәтү турында» 2004 елның 8 декабрендәге 63-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законына (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2004, № 12 (II өлеш), № 12 (III өлеш); 2005, № 2; 2006, № 2 (I өлеш); 2007, № 11; 2008, № 5 (I өлеш), № 12 (I өлеш); 2009, № 12 (I өлеш); 2010, № 10 (II өлеш); 2011, № 8 (I өлеш), № 10 (I өлеш); 2012, № 6 (I өлеш), № 7 (I өлеш); 2013, № 1, № 5; 2014, № 4, № 6 (II өлеш), № 7, № 12 (II өлеш); 2015, № 4, № 12 (I өлеш); Татарстан Республикасы законнар җыелмасы, 2016, № 44 (I өлеш); 2018, № 1 (I өлеш), № 38 (I өлеш), № 78 (I өлеш); 2019, № 2 (I өлеш); 2020, № 57 (I өлеш), № 87 (I өлеш); 2021, № 20 (I өлеш) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 5 статьяда:
а) 1 пунктның беренче абзацында «мөрәҗәгать иткән көнгә» сүзләрен төшереп калдырырга;
б) 2 пунктта «мөрәҗәгать иткән көнгә» сүзләрен төшереп калдырырга;

2) 8 статьяның $2^1$ пунктында:
а) беренче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:
«$2^1$. Ятим балалар, ата-ана кайгыртуыннан мәхрүм калган балалар, ятим балалар һәм ата-ана кайгыртуыннан мәхрүм калган балалар арасыннан булган затлар түбәндәгеләргә хокуклы:»;
б) түбәндәге эчтәлекле яңа өченче абзац өстәргә:
«расланган квота чикләрендә «Россия Федерациясендә мәгариф турында» 2012 елның 29 декабрендәге 273-ФЗ номерлы Федераль законда билгеләнгән тәртиптә бакалавриат программалары һәм белгечлек программалары буенча укырга керү;»;

в) өченче – бишенче абзацларны тиешенчә дүртенче – алтынчы абзацлар дип санарга;

3) $9^1$ статьяның икенче җөмләсен түбәндәге редакциядә бәян итәргә: «Күрсәтелгән мәгълүматны Социаль тәэмин итүнең бердәм дәүләт мәгълүмат системасына урнаштыру һәм аннан алу, граждан тарафыннан аңа социаль ярдәм чараларын алу мөмкинлеген бирә торган вакыйгага бәйле рәвештә барлыкка килә торган хокуклары турында Социаль тәэмин итүнең бердәм дәүләт мәгълүмат системасында төзелгән персонификацияләнгән мәгълүматны, шулай ук бу чараларны билгеләү һәм бирү шартлары турындагы мәгълүматны алу «Дәүләт социаль ярдәме турында» 1999 елның 17 июлендәге 178-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә гамәлгә ашырыла.».

**2 статья**

Әлеге Закон рәсми басылып чыккан көненнән соң 10 көн узгач үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Президенты Р.Н. Миңнеханов

Казан, Кремль
2021 ел, 22 июнь
№ 42-ТРЗ